**СОВЕТ СТАРОШАЙМУРЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ШӘЙМОРЗА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Иске Шәйморза авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

202 нче елнын 29 нчы мае № 58/3

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (2019 елның 16 декабрендәге үзгәрешләр белән) нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Шәйморза авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 21 карары белән расланган Нигезләмәгә, 16 статьяның 3 пунктын түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутаты муниципаль вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче зат үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Президентына мәгълүмат бирә, Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә. Авыл җирлегенең вәкиллекле органы депутатының муниципаль вазыйфасын биләп торучы һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы зат күрсәтелгән мәгълүматларны депутат итеп сайлаганнан соң дүрт ай эчендә, аңа вакантлы депутат мандатын тапшырганнан яки аның вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыруын туктатканнан соң, шулай ук хисап чоры дәвамында «дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында»2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган алыш-бирешләрне башкарган очракта, һәр ел өчен тапшыра.

Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Чүпрәле муниципаль районының Иске Шәйморза авыл җирлегенең рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Иске Шәйморза авыл җирлеге башлыгы: И.С.Бикчуров